операциялэрдэн тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алырга хокуклы түгел.

49. Субсидия алучылар, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы финанс ягыннан тээмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамэлгэ ашыру һэм жирле хакимият тарафыннан күрсэтелгэн акчаларга ихтыяж булу яки, аларга ихтыяж булмаган очракта, күрсэтелгэн акчаларны кире кайтару турында карар кабул иткэндэ, мондый нигезлэмэлэрне хокукый акт белэн билгелэнгэн тэртиптэ һэм срокларда килешүгэ кертү мөмкинлегенэ ия (кирэк булганда).

50. Субсидия алучылар, субсидия алучылар белэн төзелгэн шартнамэлэр нигезендэ акча алучы затлар (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берэмлеклэр катнашындагы дэүлэт (муниципаль) унитар предприятиелэреннэн, хуҗалык ширкэтлэреннэн һэм җэмгыятьлэрдэн, аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкэтлэр һэм җэмгыятьлэр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) аларга карата бюджет акчалары белэн баш эш итүче тарафыннан субсидия бирү тэртибе һэм шартлары үтэлешенэ, шул исэптэн субсидия бирү нэтиҗэлэренэ ирешү өлешендэ, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һэм 269.2 статьялары нигезендэ, дэүлэт (муниципаль) финанс контроле органнарының тикшерүлэрне гамэлгэ ашыруга һэм мондый нигезлэмэлэрне субсидия бирү турында шартнамэгэ кертү хакында ризалыгын белдерэлэр.

51. Юридик зат булып торган субсидия алучыны берлэштерү, кушу яки яңадан төзү рэвешендэ үзгэртеп оештырганда, килешүдэ хокукый варис булып торган юридик затны күрсэтеп, йөклэмэдэ затны үзгэртү өлешендэ килешүгэ өстэмэ килешү төзү юлы белэн, килешүгэ үзгэрешлэр кертелэ.

52. Юридик зат булып торган субсидия алучыны бүлү, бүлеп бирү рэвешендэ үзгэртеп оештырганда, шулай ук юридик зат булып торган субсидия алучыны ликвидациялэгэндэ яки шэхси эшмэкэр булып торган субсидия алучының эшчэнлеген туктатканда (Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктның икенче абзацы нигезендэ крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы сыйфатында эшчэнлекне гамэлгэ ашыручы шэхси эшмэкэрдэн тыш), килешүне берьяклы тэртиптэ өзү турында белдерү кэгазе һэм, финанс белэн тээмин итү чыганагы булып субсидия торган һэм субсидия алучы тарафыннан үтэлмэгэн йөклэмэлэр турындагы мэгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөклэмэлэрне үтэү һэм кулланылмаган субсидия калдыгын шэһэр бюджетына кайтару турында акт формалаштырып, килешү өзелэ.

## 3 бүлек. Хисаплылыкка талэплэр һэм субсидия бирү шартлары һэм тэртибе үтэлешенэ контрольне (мониторингны) гамэлгэ ашыру турында талэплэр һэм аларны бозган өчен җаваплылык

53. Субсидия алучы, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленэ кадэр срокта, субсидия бирү турында шартнамэдэ билгелэнгэн форма буенча нэтиҗэлелек күрсэткечлэренэ ирешү турында Башкарма комитет адресына хисап тапшыра.

54. Башкарма комитет, Субсидия алучыдан килгэн көннэн башлап 15 эш көне эчендэ, хисапны тикшерүне гамэлгэ ашыра.

55. Башкарма комитет субсидия бирү турындагы шартнамэдэ субсидия алучы тарафыннан өстэмэ хисап бирү срокларын һэм формаларын билгелэргэ хокуклы.

56. Башкарма комитетның шэһэр хуҗалыгы һэм халык яшэешен тээмин итү идарэсе субсидия алучы тарафыннан субсидиялэр бирү тэртибе һэм шартлары үтэлешен тикшерүне гамэлгэ ашыра, шул исэптэн субсидия бирү нэтиҗэлэренэ ирешү өлешендэ.

57. Башкарма комитетның финанс идарэсе гамэлгэ ашыра:

